Бүгенге санда:



Иткә дә регламент бар.
Һәм ул күп кенә сораулар тудыра. 2 бит.


# Дуслык
Дружба

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

Җомга 30 гыйнвар 2015 ел

№ 6 (10535)


**31 гыйнварга һава торышы:** болытлы һава; урыны белән кар; җил көньяктан, 2-3 м/с; температура көндез -15°С, төнлә -12°С

# Һәр балага гаилә җылысы кирәк



Автор фотосы

КОМИССИЯ ГАЛИЧИННАР ГАИЛӘСЕНДӘ

**Кичә районда балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе эшләде.**

Ул Нурлат районында тәрбиягә бала алып үстерү буенча эш тәҗрибәсен өйрәнде. ТР Премьер-министры урынбасары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе рәисе Васыйл Шәйхразиев җитәкчелегендәге делегация эшне тәрбиягә бала алып үстерүче Мамык авылыннан башлады. Комиссия район башлыгы Равил Кузюров озатуында тәрбиягә бала алып үстерүче ике гаилә – Ванчуриннар һәм Галичиннар гаиләсе белән якыннан танышты. "Ел хәйриячесе-2012" республика конкурсы җиңүчеләре, фермерлык хуҗалыгы алып баручы Ванчуриннар бүген үзләренең 2 балаларыннан тыш, тагын 10 сабыйга гаилә җылысы биргәннәр. Күптән түгел бирелгән иркен йортта балалар һәм аларның шөгыльләре өчен бөтен мөмкинлек тудырылган. "Ел хәйриячесе – 2013" республика конкурсы җиңүчеләре, тәрбиягә 16 бала алып үстерүче ишле гаилә Галичиннарда булу да кунакларда уңай тәэсир калдырды.

Мамык авылының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча җәмәгать комиссиясе утырышында аның рәисе, авыл җирлеге башлыгы Алия Ахуньянова хисап тотты. Тәрбиягә бала алып үстерүче авылның кураторы, шул исемдәге клуб җитәкчесе Оксана Ванчуринаның чыгышы да тыңланды. Ул агымдагы елга планнар белән дә уртаклашты.

Көннең икенче өлешендә шәһәр Мәдәният сараенда балигъ булмаганнарның хокук бозуларын һәм күзәтүчесезлеген профилактикалау субъектлары вәкилләре катнашында киңәшмә үтте. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлеге начальнигы Зөлфия Мусабирова, ТР Премьер-министры урынбасары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе рәисе Васыйл Шәйхразиев чыгышларында тема бар тулылыгында яктыртылды. Чарада йомгаклау сүзе белән район башлыгы Равил Кузюров чыгыш ясады.

*(Тулырак – киләсе санда).*

**Зилия ӘКСАНОВА**

## КЫСКА ХӘБӘРЛӘР

### ШӘЙМИЕВ ИНТЕРВЬЮ БИРДЕ

Чәршәмбе көнне "Нурлат" ТРКсы легендар райком секретаре Габбас Гыйматдиновның 90 еллыгы уңаеннан ТРның беренче Президенты, ТР Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиевтан интервью алдылар. Якын көннәрдә Минтимер Шәриповичның истәлекләре тулы вариантта җирле телевидениедә эфирда биреләчәк.

### ФЕРМЕРЛАР ХИСАП ТОТТЫ

Кичә районның фермерлар ассоциациясенең еллык җыелышы булды. Ассоциация җитәкчесе Эдуард Иванов хисабыннан соң фермерлар бүген үзләрен борчыган проблемалар, якын киләчәккә планнары турында сөйләштеләр.






ШӘҺӘР

## Быелгы кыш юлларны киңәйтә

**Махсус техника да күренми, ә юллар кардан арындырылып кына калмаган, киңәйтелгән дә. Шәһәр урамнарында кар көртләренең юкка чыга баруына бик азлар гына игътибар итми калгандыр, мөгаен.**

ТКХ идарәче компаниясендә моны коммуналь хуҗалык хезмәтенә эш технологиясен белүче юлчылар алыну белән аңлаталар.

Идарәче компаниянең эш көне төнлә, шәһәрлеләр йоклаган һәм юл хәрәкәте тыныч вакытта башлана.

- Көн саен шәһәр урамнарыннан 1000 кубометрга кадәр кар чыгарыла, - ди предприятие инженеры Вера Иванова. – Кар чистарту һәм чыгаруда 4әр тәягеч һәм "КамАЗ", 3 МТЗ, 2 катнаш юл машинасы, автогрейдер, ротор катнаша. Кергән заявкалар буенча АГП чыга.

Кичә, мәсәлән, техника герелтесе иртәнге 3тә дә тынмаган иде әле. Димәк, иртәнгегә машиналарга да, җәяүлеләргә дә юл булачак.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

# РАЙОН ТОРМЫШЫ

КАПИТАЛЬ РЕМОНТ – 2015

## Тәрәзәләре көлеп тора

**Агымдагы елда районның өч урта белем бирү учреждениесе – Фома, Колбай Мораса һәм шәһәрнең 2нче урта мәктәпләре капиталь ремонтланачак. Фома һәм шәһәрнең 2нче урта мәктәбендә инде эшләр башланган, ә колбай морасалылар аңа февраль аенда керешмәкчеләр.**

– Мәктәпләрне капиталь ремонтлау программасына барлыгы 22 мәктәп кертелгән иде, - ди район башкарма комитетының мәгариф бүлеге җитәкчесе Линар Маняпов. – Дүрт ел эчендә районда 13 мәктәп капиталь ремонтланды. Программага 33 елдан артык хезмәт иткән белем бирү учреждениеләре сайлап алынды.

Фома урта мәктәбендә капиталь ремонт эшләре көзге каникуллар чорыннан ук алып барыла.

– Мәктәптәге 74 тәрәзәнең 60ы алмаштырылды, - ди мәктәп директоры Хәлим Сафиуллин. - Хәзер "СК Лидер" җәмгыятe хезмәткәрләре түбәне алмаштыру эшләре белән мәшгуль, аның яртысы профнастил белән ябылды инде.

Ярты гасырлык бина кабинетларында мәктәп җитәкчелеге моңа кадәр үк төрле грант акчаларына евроремонтлар да ясаган булган инде.

- Иң мөһиме, бинаның электр челтәрләре, җылылык системасы яңартыла, - ди директор. – Аннан ишекләр алмаштырыла, җылы бәдрәф, чишенү бүлмәсе төзеләчәк, мәктәпне тышлау да планлаштырыла.

Шәһәрнең 2нче урта мәктәбендәге капиталь ремонт эшләрен исә подрядчылар спортзал түбәсеннән башлаганнар.

- Срокларны сузмыйча, эшләрне яңа уку елына тәгәлләргә кирәк, - ди Линар Нурисламович. – Ремонт эшләре уку-укыту процессына комачауламаячак. Шуңа да ремонтның эчке якта башкарыла торганнарын каникуллар чорына калдырдык.



Автор фотосы

БҮГЕН МӘКТӘПНЕҢ ТҮБӘСЕН АЛЫШТЫРУ ЭШЛӘРЕ БАРА

**Зилия ӘКСАНОВА**

ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ



Автор фотосы

ТӨП НИГЕЗЛӘМӘЛӘРНЕ НАИЛ ГӘРӘЕВ ҖИТКЕРДЕ

## Тренировкаларга әзерлек бара

**Чәршәмбе көнне Нурлатта быелның 18 һәм 19 февралендә үтәчәк штаб тренировкаларына әзерләнделәр.**

Татарстан Республикасының граждннар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләү өлкәсендә төп чаралары планы нигезендә февральдә район территориясендә гражданнар оборонасы буенча чараларны тәэмин итүгә әзерлекне бәяләү буенча эш үткәреләчәк. Россия МЧСының Татарстан Республикасы буенча Гражданнар оборонасы өлкәсендә вәкаләтләрне тормышка ашыру бүлеге начальнигы урынбасары Наил Гәрәев аның максатларын аңлатты, һәр службага һәм эвакуацияләнгән халыкны кабул иткәндә килеп туарга мөмкин булган моментларга җентекләп тукталды. Ул узган елда гражданнар оборонасы өлкәсендә бәяләнгән 13 район һәм шәһәр арасында ике районның начар бәя алуын билгеләп үтте. Быел шәһәр һәм авыл районнары арасында Нурлат районы да бәяләнәчәк.

- Гражданнар оборонасы буенча чараларны үткәрүгә җәлеп ителгән экстрен службалар гадәттән тыш хәлләргә әзерлекнең югары дәрәҗәсен күрсәтергә тиеш, - дип ассызыклады Наил Гәрәев.

Киңәшмә барышында Наил Гәрәев гражданнар оборонасы буенча документлар, шул исәптән ТРда гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы Нигезләмә белән дә таныштырды.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

ХАЛЫК ҖЫЕННАРЫНДА

## Эш-планнар да, тәкъдимнәр дә бар

### ЧИСТА СУ ЭЧӘРСЕЗ!

Елаур авыл җирлегендә узган гражданнар җыенында район башлыгы Равил Кузюров авылда быел су проблемасы тулысынча хәл ителеп бетәчәк, диде. Бу эш "Чиста су" республика программасы ярдәмендә башкарылачак икән. Шулай ук юллар һәм авыл урамнарын яктырту өстенлекле юнәлешләрдән булачак, дип билгеләп үтте район башлыгы.

Авыл җирлеге башлыгы Галина Кульметьева да узган ел башкарылган эшләргә нәтиҗәләр ясаганнан соң, быелга планнарын җиткерде. Мисал өчен, тиздән биредә үзара салым буенча референдум уздырмакчылар. Һәм әлеге салымнан җыелган акчага Тимерличка аша салынган күперне ремонтларга исәп тоталар. Җирлектәге дүрт авылда кибетләр юк, һәм бу мәсьәлә дә бүгенге көндә кискен проблемаларның берсе. Бу мәсьәләне дә Равил Кузюров үзенең контроле алды, хәл итү юлларын эзләргә вәгъдә бирде. Район башлыгы шулай ук Елаурдагы интернат-мәктәпне 2016 елда капиталь ремонт программасына кертү мәсьәләсен дә карыячакларын җиткерде.

### ТИМЕРЛЕКТӘ КАРП ҮРЧЕТӘЛӘР

Тимерлек авыл җирлеге җыенында җирлек башлыгы Владимир Гаврилов бу хакта сөенеп хәбәр итте.

– Моңа кадәр шәхси кулларда булган буабызны җирлек исеменә рәсмиләштердек, анда карп маймычлары җибәргән идек. Алар ярыйсы ук үсте: бер килолыларга кадәрлеләре дә бар. Хәер, кайберәүләр авыз итеп карарга өлгерде инде. Гомумән, телисән һәркем буадан кармакка балык тота ала, – диде ул. Моннан тыш, Тимерлек җирлегендә мәгезле эре терлек саны да сизелерлек арткан. Монда республика һәм район җитәкчелеге тарафыннан шәхси хуҗалыкларга ярдәм дә үз йөгынтысын ясады, диде җирлек башлыгы. Демографик яктан да сөенерлек хәләр бар: быел мәктәпне 4 укучы тәмамласа, яңа уку елында 7 бала килүен көтәләр икән. Җыенда катнашкан район башлыгы Равил Кузюров та әйбәт хәбәр ирештерде: быел фермер Кирилловның хуҗалыгына республика программасы буенча асфальт юл түшәләчәк, диде ул. Гомумән, бу төбәктәге авылларның инфраструктурасын үстерү район җитәкчелегенең иң өстенлекле юнәлешләренннән булуын да әйтте. Җыенда кәрәзле элемтә, дересрәге, аның булмавы мәсьәләсе дә күтәрелде. РУЭС вәкиле бу уңайдан яңа база станцияләре төзелүен әйтте һәм җәйгә Тимерлектә дә мобиль телефоннар аша сөйләшә башлаячаксыз, дип вәгъдә бирде.

### ТУМБАГА ДИСКУССИЯ МӘЙДАНЧЫГЫ КИРӘК

Яңа Тумбада узган гражданнар җыенында халык үтә актив булды. Мисал өчен, Яңа Тумба эшмәкәре Михаил Сосипаторов авылда төрле көнүзәк проблемаларны уртага салып фикер алышу, аларны хәл итү юлларын эзләү максатыннан, дискуссия мәйданчыгы оештырырга тәкъдим итте. Бу идеяне Равил Кузюров та хуплады һәм монда нигез итеп ТОСларның мисалын алырга була, диде.

Җирлек башлыгы Леонид Осипов җирлектә башкарылган эшләргә йомгак ясады, алдагы елга өстенлекле бурычларны да билгеләде. Башкарылган эшләрдән иң сөенечлесе – авылның "Чиста су" республика программасына кертелүе. Бүгенге көндә бу программа буенча эшләрнең 75 проценты башкарылган. Шулай ук Октябрина белән Яңа Тумба арасында да юл тәртипкә китерелгән. Равил Кузюров быел авылга су тулысынча кереп бетәчәк, диде. Шулай ук авыл урамнарын яктырту буенча республика программасына корректировкалау ясылы белән Яңа Тумбаның да кертеләчәген әйтте.

**Илназ МӨБАРӘКШИН**

ХӘБӘРЛӘР

### ХӘЛ БЕЛЕШТЕЛӘР

**"Гармония" халыкка комплекслы социаль ярдәм күрсәтү үзәге белгечләре Хәрби дан көнендә традициягә дәвам итеп, сугыш вакытында Ленинград камалышын кичергәннәрнең өйләренә бардылар.**

Алар өлкәннәргә район җитәкчелегеннән зур булмаган бүләкләр тапшырдылар һәм матур теләкләр җиткерделәр.

Ленинград камалышын тулысынча өзүгә быел 71 ел булды. Бүгенге көндә районда әлеге коточкыч вакыйгаларның 6 шаһиты гомер кичерә.

**Маргарита ЛИТТА**

### КАГЫЙДӘ БОЗСАҢ, ҖАВАП ТОТАРСЫҢ

**Республиканың Дәүләт алкоголь инспекциясе нәтиҗәләр ясады.**

Чистай территориаль органы хезмәткәре Алия Гатина әйтүенчә, Нурлат районында алкогольле һәм спиртлы продукциянең законсыз әйләнешен ачыклау буенча 65 тикшерү уздырылган, 51 закон бозу очрагы ачыкланган. Хокук бозуларның күпчелеге ярлыклы срогы чыккан продукция сатуга, шулай ук халыкның өй шартларында спиртлы эчемлек ясау очракларына бәйле. Алкоголь продукциясен ваклап сатудагы чикләүләрне бозу, аны балигъ булмаганнарга сату фактлары да бар.

– Тикшерүләр дәвам итә. Гыйнвар аенда 1 хокук бозу очрагы ачыкланды. Андыйлар административ җаваплылыкка тартылачак, – диде Алия Гатина.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

### УКУЧЫЛАР СУГЫШ ТУРЫНДА УКЫЙ

**Нурлат шәһәренең балалар китапханәсе "Сугыш турында китаплар укыйбыз" проекты кысаларында үзенең укучыларын ватаныбыз язучыларының иҗатлары белән таныштыра башлады.**

Шул көннәрдә китапханәчеләр 2нче мәктәпнең 5нче сыйныфы өчен "Солдат батырлыгына башыбызны иик!" исеме астында китапларга виртуаль күзәтү оештырдылар. Балалар китапханәсе мөдире Тамара Тайменева әйтүенчә, мондый чаралар барлык яшь төркемендәге укучылар өчен дә планлаштырыла.

**Маргарита ЛИТТА**

### АУЧЫЛАРДА – КЫШКЫ СЕЗОН

**– Нурлатта ау кагыйдәләрен бозу очрагы юк, – дип хәбәр итә районның баш аучысы Ренат Мостафин.**

Пошиларга ау сезоны барышында Нурлат аучылары 12 җәнлек аткан. Хәзер алар кабан һәм куяннар аулый. Әлеге җәнлекләргә ау сезоны 28 февральгә кадәр барачак. Баш аучы билгеләп үткәнчә, соңгы арада кыргый тәлкеләрнең йорт хайваннарына һөҗүм итү очраклары бар. Мондый факт Урта Чаллы авылында теркәлгән.

**Зилия ӘКСАНОВА**

### Кабул итүгә килегез

Бүген, **30 гыйнварда, көндезге 11дән 1гә кадәр** шәһәр Мәдәният сараенда Дәүләт Советы депутаты, "Бердәм Россия" партиясе рәисе Дмитрий Медведевның иҗтимагый төбәк кабул итүе бүлмәсе җитәкчесе **Татьяна Воропаева** нурлатлыларны кабул итә.

КӨН ТЕМАСЫ

# Ит яныннан ерак кит?!.

**2015нче елның 1 маеннан сату өчен җитештерелә торган терлекне бары тик махсус сугым пунктларында гына чалырга рөхсәт ителәчәк. Бу Таможня союзының "Ит һәм ит продукциясенең куркынычсызлыгы турында"гы техник регламенты үз көченә керү белән бәйле.**

## ЯҢА ЕЛДАН – ЯҢА БӘЯЛӘР

– Апа, менә бу кисәкне карагыз әле, нинди сусыл!

Шулай дия-дия базарда ит сатучы ханым товарын тәкъдим итә. Киштә янына килеп баскан карт әбинең генә әлләни иркенәергә җае юк бугай. Шулай да тагы бер кат янчыгын ачып карагач:

– 1 кило фарш үлчәсәң генә инде, - дип куйды.

Яңа елдан бирле базарда фаршны 300 сумнан тәкъдим итәләр. Итнең сөяксез кисәкләренең килограммы исә 320-330 сумга кадәр менде. Көзен авыл хуҗалыгы ярминкәләрендә итнең килограммын 230 сумнан алып калган нурлатлыларның күбесе бәяләрнең кисәк сикерешенә карап аптырый. Әби дә бер килограмм фаршын пакетына сала-сала, канәгатьсезлеген белдерергә ашыкты.

Хәер, Яңа елдан бәяләрнең иткә генә түгел, барлык төр продукциягә артуы күзгә күренерлек булды анысы. Сәбәбен исә зур кибет челтәрләре әлеге дә баягы шул чит ил товарларына санкцияләр кертелүе белән бәйли. Тик биредә сүз үз авылларыбызда үстерелгән терлекләр турында бара. Җитмәсә, кыш – сугым вакыты, бу чорда ит бәясе елның-елында тотрыклы килде, ләбаса.

- Авылларда ит кыйммәтләнде бит, ә без итне халыктан сатып алабыз, - дип аңлатырга ашыктылар базарда ит сатучы эшмәкәрләр. – Элек авыл кешесе итен кая куярга белми аптырый торган иде. Ә хәзер өеннән үк килеп алалар. Чөнки үзебездә җитештерелгән продукциягә сорау артты. Авылларда 250 сумнан да ит табу кыенлашты хәзер.

Авыл җирлекләренең күбесендә чынлап та иткә бәяләрнең артуын расладылар. Яңа елга кадәр түмәрләп килосын 220–230 сумнан саткан булсалар, хәзер 250 сум, ди.

## РЕГЛАМЕНТНЫҢ ТАЛӘПЛӘРЕ КЫРЫС

Әмма яңа елдан бәяләрнең артуы әле беренче генә дулкын булмагае. Чөнки ит сатучылар быелдан яңа таләпләр буенча эшләргә мәҗбүр. Бу Таможня союзының техник регламенты үз көченә керү белән бәйле. Әлеге регламент инде 2013 елның ноябрь азагында ук кабул ителсә дә, аның үз көченә керү срогы башта 2014 елның 1 маена, аннан 2015 елның 1 гыйнварена кадәр ике тапкыр озайтылды. Ел башында районның кайбер ит сатучы эшмәкәрләре шуңа бәйле проблема белән очрашырга да өлгергән иде инде. Әмма гыйнвар урталарында аның янә бер срокка – 2015 елның 1 маена кадәр озайтылуы турында хәбәр килеп иреште. Техник регламент Таможня союзы территориясендә терлек чалуга һәм ит продукциясенә, аны җитештерү, саклау, күчерү, сату һәм утильләштерү белән бәйле мәҗбүри кагыйдәләрне билгели.

– Әлеге кагыйдәләр хуҗалыгында үзләре өчен терлек асраучыларга кагылмый, - дип аңлатма бирә бу уңайдан Нурлат районы ветеринария берләшмәсе начальнигы Василий Лысов. – Әмма ите сатуга чыгарыла торган терлек һичшиксез махсус мәйданчыкларда чалынырга тиеш булачак.

Махсус мәйданчыклар исә коймалап алынган территориядә, торак пункттан 300 метрдан да ким булмаган ераклыкта урнашкан булырга тиеш. Керү юлында – дезинфекцияләүче катнашма белән тутырылган тирән булмаган канау казылуы һәм территориягә керүче транспортның шуның аша узуы мәҗбүри. Мәйданчыкның эчке яктан берничә зонага бүленүе, анда канализация, суүткәргеч булуы, ә терлекне чалу ветеринария табибы контроле астында үткәрелүе шарт. Мәйданчык барлык таләпләргә дә туры килә икән, аны тиешле инстанцияләрдә теркәп, рөхсәт документлары алырга кирәк булачак.

Әйе, кагыйдәләр катгый. Әмма, билгеле булганча, Нурлат районында әлегә мондый пункт юк.

- Бездә модульле терлек чалу пункты төзеләчәк. Ул Яңа Иглай ягында булачак. Пунктның проект-смета документациясе әзер, республикадагы заводларның берсенә заказ бирелгән. Аны җәйгә кадәр төзеп бетерү планлаштырыла, – ди район башкарма комитеты җитәкчесе Әсхәт Габдуллин.

Махсус мәйданчык тәүлегенә 25 баш терлекне чалып, эшкәртергә мөмкинлек бирәчәк. Ул сафка басканнан соң итләре базарга сатуга, гомуми туклану урыннарына, эшкәртүгә китәчәк барлык терлекләрне дә шунда алып килеп билгеле бер бәя бәрабәренә чалдырырга кирәк булачак. Әлегә бәяләр турында сөйләргә иртәрәк булса да, республиканың кайбер районнарында бер мөгезле эре терлекне чалдырган өчен 2000 сумнан артыграк түләү каралганы билгеле. Моның да, һичшиксез, итнең үзкыйммәтенә өстәләчәге хак.

## "ҺӘР ФЕРМЕРГА ҮЗ СУГЫМ ПУНКТЫ КИРӘК"

Инде әйтеп үткәнебезчә, таләпләр үзләренә иткә дип терлек асраучыларга кагылмаячак. Василий Лысов әйтүенчә, алар күпләп кош-корт тотучыларга да борчу тудырмаячак. Әмма фермерлар, күпләп терлек асраучылар да бар бит әле. Мәсәлән, Колбай Мораса фермеры Закир Мостафаевның хуҗалыгында хәзер дистәгә якын мөгезле эре терлек симертелә. Тик фермер аларны чалдыру өчен Нурлатка кадәр килеп йөрүне акча түгү булачак, дип саный.

- Бер терлекне чалдыру өчен миңа Колбай Морасадан 70 чакрым ераклыкта урнашкан Нурлатка чыгып китәргә кирәк булачак, - ди ул. - Моның өчен махсус транспорт кирәк, димәк, машина яллау өчен, аннан чалу пункты хезмәтләре өчен түлисе булачак. Өстәвенә, көнең уза. Алай мәшәкатьләнгәнче, миңа терлекне алыпсатарларга биреп җибәрү җиңелрәк булачак. Бу янә без – фермерлар файдасына булмаячак инде.


Чыгымнар булмасын диючеләр үзләре дә сугым мәйданчыклары ясап куя алалар, әлбәттә. Республикада бу эшкә алынучыларга ярдәм чаралары да каралган. Закир Мостафаев та үз фермер хуҗалыгындагы бер бинада ук терлек сую урыны ясарга дип тә ниятләгән булган, әмма ветеринария белгечләре рөхсәт бирмәгән. Аның урнашкан урыны стандартларга туры килми икән – торак пункттан 500 метр булса да, терлек асрау биналарына якын урнашкан. Әмма фермер чит илдәге сыман һәр фермер хуҗалыгында сугым сую урыннары булдырасы иде, дип хыяллана. Ә яңа таләпләр кертелү шул ук коррупциягә китермәсме, дип тә борчыла.

Ничек кенә булмасын, яңа регламент – көн таләбе. Бу барыннан да бигрәк азык-төлек базарының куркынычсыз булуы өчен кирәк. Әнә, Россельхознадзор белгечләре терлекләрне ишегалдында чалганда элементар ветеринария-санитария кагыйдәләре, гигиеник таләпләр дә исәпкә алынмый һәм калдыклар да тиешле рәвештә урнаштырылмый, дип белдерә. Моннан тыш, хайваннар һәм кешеләр өчен уртак булган авырулар таралу куркынычы да бар. Ә регламентны үтәмәүчеләргә штрафлар каралган: гражданнарга ул – 1дән алып 2, вазифаи затларга 10нан алып 20, юридик затларга 100дән алып 300 мең сумга кадәр тәшкил итә.

Гади халык арасында исә яңалыкны төрлечә кабул итүчеләр бар. "Гомер буе ишегалдында чалынган терлек ите ашадык әле, берни булмады", - дип фикерен белдерде бер авылдашым. "Еш кына итнең кая, ничек чалынганын да белмисең. Таләпләр катгыйлангач, курыкмаячакбыз, тынычлап ит ашаячакбыз", - дип мөнәсәбәтен белдерүче дә булды. Әмма ул техник регламент таләпләренең шул ук ит бәяләренең артуына китерәсен уйлап бетермәде булса кирәк. Ни дисәң дә, җитештерүчеләргә тиздән мал асраудан тыш, сугым чыгымнарын да капларга кирәк булачак бит.

...Мөгаен, тиздән итнең организм өчен авыр ризык булуына ышана башларбыздыр.

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**




ЯҢА ЕЛДАН БАЗАРДА ИТКӘ ЯҢА БӘЯЛӘР БАРЛЫККА КИЛДЕ

ҖИҢҮНЕҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА




ЗИНАИДА КЛОЧКОВАГА ПРЕЗИДЕНТ КОТЛАВЫ КИЛЕП ИРЕШТЕ

# Бәрәкәтле гомер

**Чулпан авылында гомер итүче Клочковлар династиясенең педагогик стажы 200 елга җыела икән. Зинаида Ильинична үзе 40 ел гомерен укытуга багышласа, тормыш иптәше, Бөек Ватан сугышы ветераны Юрий Леонидович сугыштан соң мәктәптә рәсем, сызым, хезмәт һәм физкультура дәресләрен укыта. Бу һөнәрне хәзер аның балалары, туганнары дәвам итә.**

Гыйнвар аенда үзенең 90 яшьлек юбилеен билгеләп үткән тыл хезмәтчәне, хезмәт ветераны Зинаида Клочкова озын гомерле булуының серен нәселдән килә, дип саный.

– Бабам 97 яшькә җитсә, әти-әниләр 89га кадәр яшәделәр, - ди Зинаида Ильинична. – Билгеле инде, балаларым һәм оныкларымның тәрбиясе, якыннарымның игътибары да үз йогынтысын ясагандыр.

Кирпичный поселогында 7 ел укыганнан соң, Елаурда 10 еллык мәктәпне тәмамлау белән Зинаида Мамык мәктәбенә счетовод булып эшкә урнаша. Зинаида Клочкованың озын гомер юлы төрле вакыйгаларга бик бай була.

– Мин 10 сыйныфны тәмамлаганда, сугыш башланды, - ди ул. – Менә шул чордан алып мин хезмәттә булдым. Әтине сугышка алдылар. Гаиләгә ярдәм итәсе, эне-сеңелләрне аякка бастырасы бар. Михайловка урта мәктәбендә укытучы, ә 1946 елдан алып Чулпан урта мәктәбендә башлангыч сыйныф укытучысы булып эшләдем. Үз гомеремдә Чулпан урта мәктәбендә генә дә 8 чыгарылыш ясарга насыйп булды. Шөкер, укучыларым үземне беркайчан да онытмыйлар.

Хезмәт ветеранын балалары, оныклары, укучылары гына котлап калмады, ә 3 гыйнварда билгеләп үткән гомер бәйрәмендә РФ Президенты Владимир Путинның юбилей белән тәбрикләү открыткасы да килеп ирешге. Зинаида Ильиничнага "Бердәм Россия" сәяси партиясенең җирле бүлекчәсе секретаре Равил Кузюровның да бүләкләре тапшырылды.

– Игътибар һәм кайгырту булганда, бабамның рекордын да уздырырга мөмкин әле, - диде тыл хезмәтчәне уенын-чынын бергә кушып һәм игътибарлары, кайгыртулары өчен җитәкчеләргә олы рәхмәт сүзләрен дә җиткерде.

**Зилия ӘКСАНОВА**

# Экранда – камалыш турында көндәлек

**"Гармония" социаль хезмәт күрсәтү үзәгенең "АрлеКино" клубындагы чираттагы занятие Ленинградны фашистлар камалышыннан азат итүгә багышланган иде.**

Үзәкнең канаты астындагы гаиләләрдәге үсмерләргә "Блокадный дневник Тани Савичевой" документаль фильмы күрсәтелде. Бу фильм сугыш еллары хроникасы һәм тере шаһитларның камалыштагы шәһәр турындагы хатирәләреннән гыйбарәт. Шәһәр камалышы фаҗигасенең бөтен асылы кыска гына 9 язмада чагылдырылган. Аларны исә Ленинград мәктәбе укучысы Таня Савичева үзенең көндәлегенә теркәп барган. 11 яшьлек кыз барлык туганнарының үлгән көнен һәм вакытын язып калдырган. Сугыштан соң аның бу кенәгәсе шәһәр оборонасы музеена эләгә һәм бик тиз арада иң истәлекле экспонатларның берсенә әверелә. Балалар Бөек Ватан сугышы турында фильмнарны ешрак күрсәтүебезне сорадылар.

**Инга САДОВНИКОВА,**
социаль эш буенча белгеч

# МАНЗАРА

ГАББАС ГЫЙМАТДИНОВНЫҢ 90 ЕЛЛЫГЫНА

## Эшне күрде, рәхмәтен кызганмады

**Хәниф Әюпов, 1982–99 елларда ДАИ бүлеге җитәкчесе, Татарстанның атказанган юл хезмәткәре, Түбән Нурлат микрорайонының ТОС рәисе:**

*– Габбас Кыям улы Гыйматдинов эшләгәнне күрә белде һәм рәхмәт сүзләрен кызганмады. 80нче еллар башында мине үз кабинетына чакырып алып зур гына эш йөкләде. Районнагы бер яхшы "Волга" машинасын Нурлатның бер түрәсе Әлмәт шәһәренә "саткан," шуны яңадан районга кайтарырга кирәк, ди Габбас Кыямович. СМУ начальнигы Вахит Арсланов белән Әлмәткә чыгып киттек. Әгәр машинаны кайтарып булса, транспорт СМУга бирелергә тиеш иде. Әлмәтнең ул вакыттагы ДАИ начальнигы Таһир Мусиннан машинаны табып бирүен үтендем. Ул булышты. Әлмәтнең ДАИ бинасы каршына килеп баскан машина шофёрыннан "Волга"дан кирәкле әйберләреңне ал, без машинаны карарга алып китәбез, дип ачкычларны алдым да, рульгә утырып Нурлатка "элдерттем". Юлда кайтканда машинага яңа номерлар куйдык, яңа техник талон яздык. ДАИ хезмәткәрләре сезне барыбер тоткарлаячаклар, дип кисәтеп куйдылар. Әмма без төп трассадан түгел, авыллар аша Нурлатка исән-имин кайтып җиттек. Дөрес, Нурлатка үз машинабызны кире кайтару вакыйгасы бераз шаушу тудырды анысы. Безне ул вакытта Габбас Кыямович үзе каршы алып, рәхмәт сүзләре җиткергәне әле дә хәтердә.*

*Тагын бер вакыйга салкын көз аенда булды. Габбас Кыямович кабинетына чакырып ике егетне Әхмәт белән Чишмә авыллары арасында ярымшәрә килеш мотоцикл руле артында күрүен әйтте һәм тиз арада аларның кем булуларын ачыкларга кушты. "Табарга тырыш, мотоциклның утыргычы да юк" ,- дигән сүзләр миңа әлеге фактны ачарга ярдәм итте дә. Мин әлеге вакыйга турында коллективка җиткердем. Һәм шунда коллегаларым рейд вакытында бер "ИЖ" мотоциклын тоткарлауларын һәм аның утыргычын салдырып алуларын әйттеләр. Менә шулай егетләрне тоткарлап, Габбас Кыямовичка чакырттык. Егетләр ДАИ хезмәткәрләре утыргычны алгач, үз киемнәрен салып, алардан утыргыч ясап куйганнар икән. Бу хакта алар райком секретаре кабинетында сөйләделәр. Райондагы һәр гадәти булмаган очракка игътибарлы иде җитәкче. Оператив эш иткән өчен без бу юлы да рәхмәт сүзе ишеттек.*

**Зилия ӘКСАНОВА** язып алды

ИҖАТ


Автор фотосы

ИЛҺАМ КАМАЕВНЫҢ ГАРМУНЫ – ГОМЕРЛЕК ДУСТЫ

## Гармун сайрый да сайрый...

**Авылларда гармунчылар кимеп, гармун моңы югала башлаган елларда халыкның аңа тартылуы арта гына бара.**

Моны әлмәтле Илһам Камаев та куәтли. Ул– гомерен хезмәткә, күңелен гармун моңына багышлаган моңсөяр кеше. Озак еллар Яңа Әлмәт мәктәбендә, соңгы ике елын туган авылы Колбай Мораса мәктәбендә технология укыта. Берүк вакытта Илһам Әдип улы – алыштыргысыз гармунчы да.

– Мәктәптә үткән чараларның һәрберсендә музыкаль өлешне аңа алып барырга туры килә, һәм ул беркайчан да аннан баш тартмый,– ди Колбай Мораса гомумбелем бирү мәктәбе директоры Мансур Вәлиев. Алай гына да түгел, Илһам Камаев үз тирәсенә моңга тартылган балаларны туплап, аларны гармун серләренә өйрәтергә дә иренми икән әле. Хәер, бер үтенечне дә кире кага белми, диләр аның турында. Авыл мәдәният йортларында концерт булса да, очрашулар үткәрсәләр дә кичәләрне Илһам гармуны бизи. Әле менә бу авыл үзешчәннәренең хисап концерты барган вакытта Илһам Әдиповичның аерата да "каderле" көннәре: сәхнәгә менгән Әлмәт авыллары үзешчәннәренә дә, әмзәләләргә дә нәкъ менә ул уйнады, халыкка гармун моңы бүләк итте.

**Сәкинә ХӘЙРУЛЛИНА**

БЕЗНЕҢ КОНКУРС

## Ишегалдында – кар шәһәрчеге


Автор фотосы

**"Безнең ишегалдында – кар фигуралары параде", – дип район газетасы игълан иткән конкурста катнашырга теләк белдерделәр "Чыршыкай" балалар бакчасы тәрбиячеләре Людмила Козлова һәм Вера Шабалова.**

Үз участокларында алар балалар теләге буенча кардан автомобиль, чыршы, кар бабай һәм тау ясап куйганнар. Балалар, саф һавага чыккач, рәхәтләнеп тау шуалар, әйлән-бәйлән уйныйлар икән. Күрше участокларга экскурсияләргә дә йөриләр. Бакча территориясендә коллектив көче белән кардан башка фигуралар да ясалган.

**Маргарита ЛИТТА**

ПРОБЛЕМА

## Урам этләре бәхәс тудыра

**Газетабызның электрон сайтында хуҗасыз этләрне тотулары турындагы хәбәребез халыкта ризасызлык уятты. Без анда этләрне Димитровградтагы приютка җибәрәчәкләр, дип язган идек.**

"**Надежда:** *Ялган бу! Димитровградта питомник юк. Барлык хайваннар да адилин белән үтереләчәк*".

"**Ирина Чернышева:** *Моның белән эшмәкәр түгел ә кансыз зат шөгыльләнә. Барлык этләр дә үтерелә...*"

Газетабызның электрон адресына исә Димитровградта яшәүче Ирина Коршуновадан мондый хат килде: "...Сезнең районда кансыз адәм хуҗасыз этләрне даими рәвештә үтереп тора, ул үзенең эш-гамәлләрен аларны йоклатып, соңрак Димитровград шәһәрендәге приютка җибәрәм дип аңлата. Ә бит безнең шәһәрдә берниндиде дә приют юк..." Телефоннан сөйләшкәндә, Ирина Коршунова үзен хайваннарны яклау төркеме әгъзасы дип атады һәм үз эш алымнары турында сөйләде: алар иясез этләрне ашатып торалар, аларга хуҗалар эзлиләр икән. Без дә хайваннарга кешелекле мөнәсәбәт яклы. Әлеге хат авторы һәм аның якташлары сыман ук шәһәребез урамнары куркынычсыз булсын дип тә кайгыртабыз. Һәм шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Венера Мингалиеваның җавабы хайваннарны яклаучыларны да, йортларында эт-песи асраучыларны да тынычландырыр, дип уйлыйбыз:

- Йортсыз хайваннар, шул исәптән этләр һәм песиләрне тоту һәм асрау Димитровградтан шәхси эшмәкәр Мадьянкин белән килешү нигезендә алып барыла. Бу – әлегә безне ишеткән һәм проблеманы өлешчә булса да чишәргә ярдәм итүче бердәнбер фирма. Бу эш контрольсез алып барылмый. Без республиканың "Зоозабота" яшьләр иҗтимагый хәйрия оешмасы алдында хисап тотабыз. Узган елда без "ШЭ Мадьянкин" белән 100 хуҗасыз этне тотуга 90 мең сумга килешү төзегән идек, һәм алар безнең эшчәнлекне уңай бәяләделәр. Шуңа без быел да әлеге шәхси эшмәкәр белән хезмәттәшлегебезне дәвам иттерергә булдык. "ШЭ Мадьянкин" белән килешүдә этләр атып һәм йоклатып үтерелми, диелгән. Аларны питомникта асрауга килгәндә, чаралар стерильләштерү һәм кастрацияләүгә генә кайтып калмый, хуҗасыз этләрне ветеринар йогышлы авыруларга да тикшерә. Тотылган хайванга исәпләү карточкасы тутырыла.

*2014 елда районда хайваннар (араларында хуҗасызлары да бар) тешләвеннән 147 кеше зыян күргән.*

Хуҗасыз этләр проблемасы бүгенге көндә генә килеп туган нәрсә түгел. Кемнәрдер урамда өерләре белән йөрүче этләрдән, икенчеләре проблеманы хәл итү методларыннан зарлана. Һәм, кызганычка каршы, бу яктан сайлау әлләни зур түгел. Берничә ел элек Нурлатта хуҗасыз этләр өчен приют та булдырырга теләк белдергәннәр иде, әмма ул барып чыкмады. Безнең шәһәр җитәкчелеге дә якташларыбыз арасында Ирина сыман этләр һәм мәчеләрне яңа хуҗаларга урнаштыру өчен яклау төркемнәре оештырырга теләк белдерүчеләр табылса, шат кына булыр иде дә бит. Әмма әлегә бу вакансия буш һәм булганы белән канәгатьләнергә туры килә.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

***nurlat-tat.ru сайтында әлеге тема буенча үз фикерегезне калдырыгыз***

СОРАУ-ҖАВАП

## Газ исәпләгечләре мәҗбүри түгел

**"Дуслык" район газетасына берничә укучы газ исәпләгечләре кую мәсьәләсе буенча шалтыраттылар. Бүгенге көндә исәпләгеч кую мәҗбүриме, дип кызыксыналар алар. Без бу сорауны газ службасына юлладык һәм "Нурлатгаз" идарәсенең баш инженеры Альберт ГАЛӘВЕТДИНОВ имзасы белән җавап алдык.**

*– 2015 елның 1 гыйнвареннан энергия саклау һәм энергия нәтиҗәлелеген күтәрү турындагы Федераль законның фатирларга һәм йортларга газ исәпләгечләре куюга кагылышлы 13нче маддәсенең 1нче өлешенә төзәтмәләр үз көченә керде. Аның нигезендә, әгәр дә табигый газ файдалану сәгатенә 2 куб. метрдан артмаса, көнкүреш газ исәпләгечләре кую мәҗбүри түгел. Бу – көнкүреш газ плитәләре куелган фатирлар һәм торак йортларга кагыла.*

**Сирень СӘМӘРХАНОВА** әзерләде

СПОРТ

# Директорлар да кушылды

**Быелдан укытучылар арасындагы Спартакиадада педагогик хезмәткәрләр генә түгел, ә директорлар да катнашачак. Алар чаңгы узышында һәм волейболда үз осталыкларын күрсәтәчәк.**

Спартакиаданың узган атнада 9нчы мәктәптә үткән район этабында исә мөгаллимнәр дә, җитәкчеләр дә шактый актив булды. Ярышларда барлык мәгариф учреждениеләре дә катнашты, ди сөенеп мәгълүмати-методик үзәк методисты Наталия Хәмидуллина. Мәгариф хезмәткәрләре чаңгы спорты, өстәл теннисы, турнikта тартылу һәм отжимание кебек төрләрдә көч сынаштылар һәм спартакиаданың республика этапларына әзерлекләрен сынадылар. Ярышларның чаңгы төре исә "Чияле Алан" ял базасында үтте. Монда I урынны Төрнәс мәктәбе директоры Владимир Михейкин яулады. II урында – 4нче мәктәп җитәкчесе Солтан Әхмәтҗанов, IIIдә – район мәгариф идарәсе начальнигы Линар Маняпов. Хатын-кызлар арасында Мамык мәктәбе директоры вазифаларын башкаручы Людмила Павлованы куып тотучы булмады. Татьяна Алексеева (Елаур мәктәбе) һәм Зинаида Анисимова (Андреевка) II-III урыннарны бүлештеләр. Өстәл теннисында I урыннарны Әнисә Хәмәтҗанова (Кәкре Атау) һәм Вахит Вәлитов (3нче мәктәп) яуладылар. Башка призлы урыннар Елена Әхмәдиева (№1), Татьяна Смолина (№2), Рәфис Гыймалетдинов (Киекле) һәм Йосыф Садыйковта (Киекле). Турникта иң күбе 2нче мәктәп укытучысы Эмил Галләмов тартылды. IIдә – Рәфис Гыймалетдинов, IIIдә Әсләм Кәбиров (Кизләү) һәм Александр Ендиряков (Егоркино). Хатын-кызлар отжиманиедә ярышты һәм иң яхшы нәтиҗәне Каравыл Тавы мәктәбенең физкультура укытучысы Ольга Евсеева күрсәтте, Лариса Мазилкина (№1) белән Татьяна Николаева (Егоркино) II-III урыннарны бүлештеләр. Бүген директорлар һәм мөгаллимнәр Спартакиаданың финал этабына әзерләнә. "Спартакиаданың барлык сигез төре буенча да финал ярышлары 20 февральдә Кукмарада узачак, командаларыбыз әзер", – ди район мәгариф бүлеге начальнигы Линар Маняпов.

# "Ледок" Казаннан кача алырмы?

**Нурлатның 2002 елгы "Ледок" хоккей командасы Россия беренчелеге кысаларында чираттагы уеннарын Лениногорскида уздырды.**





БЕРЕНЧЕЛЕКНЕҢ ИҢ ЯХШЫ БОМБАРДИРЛАРЫННАН БЕРСЕ – "ЛЕДОК" УЕНЧЫСЫ ИНСАФ МИФТАХОВ ҺӨҖҮМДӘ

Җирле "Нефтяник" командасы белән беренче уенда нурлатлылар оттырды, ә икенче матчта 4:1 исәбенә өстен чыкты. Шул рәвешле, бүгенге көнгә "Ледок" 24 очко белән Б төркеменең А подгруппасында җиденче урында бара. Әмма, команданың тренеры Александр Елагин әйтүенчә, бу остазны дә, яшь хоккейчыларның үзләрен дә әллә ни канәгатьләндерми икән. Дөрес, плей-офф уеннарына һичшиксез чыгачаклар алар.

– Плей-офф системасы буенча, турнир таблицасының аскы өлешендә урын алганнар икенче төркемдәге югарыда урнашкан командалар белән уйный, – дип аңлата Александр Елагин. – Димәк, бүгенге көннән чыгып карасак, безгә хәлиткеч уеннарның беренче этабын ук Казанның "Зилант"ына каршы уздырырга туры киләчәк. Әлбәттә, көчле команда белән уйнавы кызык анысы, тик беренчелекне беренче этапта ук төгәллисе дә килми бит. Сер түгел, "Зилант"ка чыксак, безнең шансларр әллә ни зур булмаячак.

Хәер, "Ледок"ның турнир таблицасындагы хәлен төзәтергә мөмкинлеге булачак әле. Беренчелекнең төркем этабында нурлатлыларга "Волгарь" (Тольятти) һәм 24 уенда нибары 1 очко туплаган "төпле" аутсайдер "Кристалл" (Балаково) белән 2шәр очрашу уздырасы калды.

"Ледок" хоккейчыларының шәхси статистикасына килгәндә, Инсаф Мифтахов әлегәчә турнирның иң яхшы бомбардирлары арасында. Гол+пас системасы буенча аның 27 очкосы бар (14+13). Илья Кузнецовны их яхшы снайперлар исемлегенә күрергә була – ул көндәшләре капкасына 15 гол кертә алган. Моннан тыш, беренчелекнең иң тупас уенчысы да "Ледок" командасында: Камил Кәримуллин 49 штраф минуты белән әлеге исемлекнең башында тора.

КЫСКАЧА

**КИКБОКСИНГ.** Башкортостанның Туймазы шәһәрендә кикбоксинг клублары арасында Россия беренчелеге үтте. Анда Нурлат балалар-үсмерләр спорт мәктәбе шәкертләре дә катнашты. "Гадәттәгечә, турнир бик югары дәрәҗәдә үтте, хәтта Амур, Камчатка якларыннан да спортчылар килгән иде, 300дән артык спортчы көч сынашты", – дип тәэсирләрен уртаклашты ДЮСШ тренеры Евгений Казаев. Нәтиҗәдә, спорт мәктәбенең яшь кикбоксчылары Руслан Никоненков – II, Ильяс Хөснетдинов һәм Булат Шәйдуллин III урыннар алып кайттылар.

**УКУЧЫЛАР СПАРТАКИАДАСЫ.** Республика укучыларының X спартакиадасы кысаларында чаңгы ярышларының финал этабы узган атнада Зәйдә үтте. Анда Нурлат районы да матур чыгыш ясады һәм республика буенча IV урын алуга иреште. Нурлат командасы өчен тренерлар Иван Белов, Валерий Трофимов, Илһам Әндаров, Владимир Шугаев һәм Александр Ендиряков шәкертләре йөгерде. Безнекеләрдән иң яхшы нәтиҗәне Айдар Әндаров һәм Анна Ефимова күрсәттеләр.

**БИАТЛОН.** Нурлат егете Георгий Крайнов биатлон буенча Идел буе Федераль округы беренчелегендә катнашырга әзерләнә. Георгий – Нурлат балалар-үсмерләр спорт мәктәбе шәкерте, бүген ул Олимпия резервы мәктәбендә белем ала. Ә биатлон буенча беренчелеккә исә Татарстан җыелма командасы составында барачак.

Илназ МӨБАРӘКШИН

САК БУЛЫЙК!

# Өй интерьерында – ут сүндергеч

**Ел башыннан янгын сүндерүчеләр 24 тапкыр вакыйгалар урынына чыгарга өлгергәннәр. Кузәтчелек эшчәнлеге бүлегеннән әйтүләренчә, 30 декабрь–16 гыйнварда торак секторда 5 янгын очрагы теркәлгән.**

– Кызганычка каршы, янгында 1 кеше зыян күрде, – диде районара ОНДның баш белгече Әлмәрис Талипов. – Ут 4 корылманы, 2 фатирны яндырды. Уттан ун кешене коткарып кала алу яхшы, әлбәттә.

Яңа ел алды көнне, 18.55тә Тельман урамында янгын турында хәбәр керде. Янгын бер предприятиенең каравылчы будкасында чыга, нәтиҗәдә каравылчының аяклары пешә. Ул исерек була, һәм ут та тәмәке тарткандагы саксызлыктан килеп чыга.

Бүлек белгече әйтүенчә, күпфатирлы йортларда янгын очраклары арткан. Мисал өчен, шундый бер очрак 16 гыйнварда Совет урамындагы йортның беренче катындагы фатирда килеп чыга.

– Хәзер фатирларда заманча җиһазлар, отделка материаллары күп, алар янган чакта бик күп токсик матдәләр бүлеп чыгара, – ди Әлмәрис Талипов. – Күршеләрнең уяулыгы, 125нче янгын часте хезмәткәрләренең белеп эш итүләре аркасында янгын сүндергән вакытта төтен тулган фатир һәм подъездлардан халыкны чыгарып булды. Әмма фатир һәм подъездга яхшы ук зыян килде. Ә янгын көнкүреш электр җиһазының төзексезлегеннән чыккан. Фатирларда янгынның кагыйдә буларак ике сәбәптән чыга – ут белән саксыз эш итү, көнкүрештәге электр җылыткыч приборларының, шулай ук фатирлар эченәдәге электр җайланмалары системасының төзексезлеге. Төзек булмаган яки кулдан ясалган электр приборларыннан файдаланырга ярамый. Фатирдагы розетка-вилкаларны да һичшиксез тикшереп торырга кирәк. Бүген фатирларга автоном датчиклар куела, һәм кешеләр аларның аз гына төтендә дә эшләп китүләрен белмиләр. Әлеге датчикларны тавышлары бик көчле, аны күршеләр дә ишетә ала. Әмма фатир хуҗалары датчикларны интерьерны боза дип, алып ташлыйлар һәм бу, янгын чыга калса, фатирны да, милекне дә юкка чыгару куркынычы тудыра.

Гап-гади пехтәлек һәм көнкүреш культурасы йортны янгыннан саклый ала. Ә бит моның өчен нибары электр приборларын, лампаларны дөрес урынга куярга, көнкүреш техникасын, электр приборларын кабызып калдырмаска, әлбәттә иде, кулдан ясалган приборлардан файдаланмаска гына кирәк. Аннан газның да шартлау ихтималы булуын онытмагыз һәм ул да аерата игътибар сорый, дип кисәтәләр күзәтчелек эшчәнлеге бүлегендә һәм өй интерьерына гадәти ут сүндергечен дә өстәргә киңәш итәләр.

> ШАЛТЫРАТЫГЫЗ
>
> **Янгын сагы службасын чакыру тел.: 112, 01.**

Сирень СӘМӘРХАНОВА
(районара ОНД материаллары буенча)

ЯШЬЛӘР





СӘХНӘДӘ - ҖИҢҮЧЕ 423НЧЕ ТӨРКЕМ ЕГЕТЛӘРЕ

# Студентлар "кәбестә тапый"

Ничек уйлыйсыз, студентның техникумга баруы белән кайтырга аермасы бармы? Юктыр, диярсез күбебез. Әмма бу ситуациягә студентлар шаянлыгы белән якын килгәндә, бик мәзәк хәл уйлап чыгарырга мөмкин икән бит. Әнә, Студентлар көненә багышлап үткәрелгән "капустника" Нурлат аграр техникумында белем алучы егет һәм кызлар шундый гадәти нәрсәләрне дә оста итеп сәхнәләштереп, рәхәтләнеп шаярыштылар. Киемнәрне конструкцияләү һәм модельләштерү белгечлеге буенча белем алучы 424 төркем студентлары яшьләрнең имтиханга әзерләнүен оста итеп сурәтләде һәм икенче урынга чыкты.

- Техникумда "капустник" әле беренче тапкыр гына үткәрелә, шулай да бик күңелле булды, - диләр әлеге төркем студентлары Рамилә белән Юлия. "Капустник"ка кураторлары Елена Туешева белән бергә әзерләнгәннәр кызлар һәм мондый чараларр төркемне берләштерү көченә ия дип саныйлар.

Беренче урынга исә 423нче төркем егетләре лаек дип табылды. Ә чара өлкән курсларда укучы яшьләр белән бергә беренче курсныкыларга да сәхнәдә үзләрен сынап карау, сәләтләрне ачыклау өчен яхшы мөмкинлек булды. Чөнки инде апрель аенда төркемнәрне техникумда КВН уеннары, ә май аенда техникумның җыелма "НАТс" КВН командасын тәбәк бәйгеләре көтә.

Техникум студентлары спортта да сынатмый. Узган җомгада гына алар барысы бердәм булып ГТО нормаларын тапшырдылар.

Лилия МӨБАРӘКШИНА

# ТӨРЛЕ. БЕЛДЕРҮЛӘР

БӘЙГЕ

## Атыш уенында “Патриотлар”җиңде



Автор фотосы

ИКЕНЧЕ УРЫН АЛГАН “РИТЭКЧЫЛАР” КОМАНДАСЫ

**25 гыйнварда “Чияле Алан” ял базасында Нурлат районы башлыгы Кубогына пейнтбол буенча чемпионат үтте.**

Чемпионат Нурлатта икенче тапкыр гына уздырыла, һәм быел анда 11 команда көч сынашты. Ярышта катнашучылардан “Татнефтеотдача”, “ТатРИТЭКнефть” ТППсы, район башкарма комитеты командалары җәйге уеннар буенча таныш инде. Быелгы уеннарга яңа катнашучылар да чакырылды. Бу – “Бердәм Россия” сәяси партиясенең җирле бүлекчәсе, прокуратура, тикшерү комитеты, экологик служба, Дәүләт алкоголь инспекциясе һәм административ комиссияне берләштергән “Звезда” командасы иде. Чемпионатка үзлектән җыелма команда туплап килүчеләр дә булды. Болар – кызларның “WINX”, егетләрдән торган “Легион” һәм шулай ук “Патриот” страйкбол клубы командалары.

Һава торышының салкын булуына да карамастан, уен кырында кызу иде. Чемпионат олимпия системасы буенча өч әйләнештә узды. Флагны кулга алып үз базасына кадәр китереп җиткергән команда җиңүче булды.

Беренче урынны чемпионатта тәүге тапкыр катнашкан, әмма тәҗрибәле “Патриот” командасы яулады. Көмеш призер исеменә “ТатРИТЭКнефть” ТППсы командасы ия булды. Бронза район башкарма комитеты командасына бирелде.

Барлык призер командалар да район башлыгы Равил Кузюровның грамоталарына һәм акчалата бүләкләргә ия булдылар. Ә җиңүче командага район башлыгы Кубогы да тапшырылды.

**Гөлназ ГАЗИЗОВА**

АВЫЛДА

## Хуҗасы нинди, йорты – шундый

**2014 ел нәтиҗәләре буенча Фома авылында традицион “Төзек йорт” конкурсында җиңүче дип Сания апа Ганиева табылды.**

Ялгыз яшәвенә карамастан, 78 яшьлек Сания Мингалимовна үз йортын һәм аның территориясен карап, тәртипләп тора икән. Узган елда ул өен профнастил белән тышлатырга һәм коймаларын яңартырга мөмкинлек тапкан. Сания әби авылның хаҗиясе дә икән әле, авыл халкы аны изге күңелле, ярдәмчел булуы өчен дә хөрмәт итә. Ә конкурста җиңүе өчен бүләкне аңа авыл җыенында район башлыгы Равил Кузюров тапшырды.

## Бергә – гомергә...

**Фома авылында яшәүче Нәгыймә һәм Әнвәр Мирзаҗановлар быел үзләренең алтын туйларын билгеләп үтәчәкләр.**

Мирзаҗановлар – авылның хөрмәтле гаиләләреннән, Нәгыймә апа гомере буена мәктәптә балаларга белем биргән, Әнвәр ага җирле хуҗалыкта хезмәт куйган, өч кыз бала тәрбияләп үстергәннәр. Гаилә бүгенге көндә дә башкаларга үрнәк булып, тату гомер кичерә.

Авылның тагы бер үрнәк гаиләсе – Миннәхмәт һәм Миннегөл Зәйнуллиннарда да быел алтын туй көтелә. Зәйнуллиннар 4 бала тәрбияләп үстергәннәр, авылда шулай ук ихтирамлы гаилә булып саналалар. Юбиляр парларны да алтын туйлары белән авыл җыенында район башлыгы Равил Кузюров котлады.

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**


### КОТЛЫЙБЫЗ!

Сөекле әниебез, әбиебез **Сәкинә Әбүбәкер кызы Камаловага** 1 февральдә 85 яшь тула. Кадерлебез, без сине шушы олы юбилееӊ белән ихлас күңелебездән тәбрик итәбез.

Без гомер буе синең уңганлыгыңа, сабырлыгыңа сокландык. Синең күңел җылың без – өч балаңа гына түгел, туганнарга да җитә иде. Әле дә шулай. Киңәшкә синең яныңа ашыгабыз, балаларыбыз әби дип өзелеп торалар. Исән-имин яшә, безнең нигез гел шулай шатлыклы очрашулардан гөрләп торсын.

Сабырлыгың, күркәм холкың
белән
Дөньябызны безнең бизәдең,
Һәммәбезне сөеп, акыл белән
Тигезләдең яшәү бизмәнен.
Олы җанлы, мәрхәмәтле
булдың,
Кичерә белдең борчу китерсәк,
Бар гамәлең, догаң
безнең өчен,
Әниебез, сиңа мең рәхмәт!

**Иң изге теләкләр белән балаларың һәм туганнарың исеменнән улың Фәрид, киленең Мәдинә, оныкларың Фәнис-Резеда, Лилия-Илмир, оныкчыкларың Зәлинә, Айсылу.**

**Зирекле** авылында яшәүче кадерлебез **Әминә Хәлиулла кызы Шәйхетдиновага 75** яшь тула.

Кадерле әниебез! Сине олы юбилееӊ белән чын күңелдән котлыйбыз. Сиңа исәнлек-саулык, озын гомер, чиксез бәхет, куанычлар, гаилә иминлеге, кайгы-хәсрәтсез көннәр телибез. Авырлыклар алдында бирешмәвеңә, зирәк, акыллы булуыңа сокланабыз. Эш-гамәлләрең, киңәшләрең, догаларың белән ярдәм итүең өчен хөрмәтлибез һәм яратабыз.

Син булганга без бәхетле,
Синең белән якты көнебез,
Безнең белән син дә
бәхетле бул,
Сиңа озын-озак гомер телибез.
Гаилә нигезе нык син
булганга гына,
Рәхмәт синең төпле сүзеңә,
Безгә булган изгелегең,
игътибарың
Савап булып кайтсын үзеңә.

**Иң изге теләкләр белән тормыш иптәшең, улларың, киленнәрең, оныкларың, оныкчыкларың, кода-кодагыйларың, барча туганнарың.**

### КҮЧЕМСЕЗ МИЛЕК

*3 бүлмәле фатир. Т. 8-927-450-82-22.

*Йорт. Т. 8-919-684-40-03.

*Үзәктә фатир, 30 кв.м, 1нче кат. Т. 8-927-031-23-45.

*Үзәктә 2 бүлмәле фатир. Т. 8-927-418-86-92.

*1 бүлмәле фатир, Мәктәп ур., 29, 46 кв.м. Т. 8-927-243-65-08.

*Йорт, Кутузов ур. Т. 8-927-243-65-08.

*Нигез салынган участок (Түбән Нурлат). Т. 8-927-415-01-51. №16-16-35/017/2011-525 м/х.

*1 бүлмәле фатир, 38 кв.м. Т. 8-937-293-28-71.

*Ашыгыч, Завод ур.да 1 бүлмәле фатир, балкон, пластик тәрәзәләр, төп коммуникацияләр – җылылык һәм канализация торбалары алыштырылган. Асфальтланган ишегалды, йорт сайдинг белән тышланган, фатир 2 катлы йортның 1нче катында. Т. 8-960-056-55-66.

*Элиталы йортта 2 бүлмәле фатир, 73 кв.м, ремонтланган, Кариев ур., 26, «Шифа» СҮ каршында. Ксения. Т. 8-929-727-12-82.

*1 бүлмәле фатир, Циолковский ур., 600000 сум. Т. 8-927-045-70-59.

*1 бүлмәле фатир, Совет ур., 189, 3нче кат, 29,2 кв.м. Т. 8-927-414-73-53.

*Үзәктә 2 бүлмәле фатир, 40 кв.м, 1нче кат. Т. 8-927-414-73-53.

*2 бүлмәле фатир, Куйбышев ур., 61а, 1нче кат. Т. 8-927-414-73-53.

*2 бүлмәле фатир, Гыйматдинов ур. Т. 8-927-456-05-69.

*Йорт, М.Җәлил ур. Т. 8-927-450-79-09.

### АВТОТРАНСПОРТ

*«КамАЗ», үзбушаткыч, 1991 елгы. Яки җиңел автомобильгә алмаштырыла. Т. 8-927-675-63-85.

*«ВАЗ-2114», 2013 елгы, люкс. Т. 8-917-259-33-23.

### БАШКАЛАР

*Утын. Т. 8-927-413-05-92.

*Такталар (усак, нарат), борыслар. Киров урманыннан. Китерәбез. Т. 8-937-003-84-85.

*Печән, салам, күп сөт һәм ит бирә торган токымлы бозаулар, бодай, вакланган бөртек, арпа, коры жом. Кыйммәт түгел. Китереп бирү түләүсез. Т.: 8-937-343-80-22, 8-909-315-99-77.

*Яңа чәшке тун, «колотый лед» (зәңгәр), 48-50ле. Т. 8-927-419-71-51.

*ШИКӘР КОМЫ-2400, ОН-970, «Юмарт» кибете. Т. 8-927-445-68-55.

*Автоматик капкалар. Т. 8-937-575-74-23.

*Стенка (Польша), 8000 сум. Сатулашу. Т. 8-927-670-38-21.

*Эре терлек ите. Т. 8-927-448-32-25.

*Бодай, арпа. Китерү – түләүсез. Т. 8-937-776-33-35.

*Бодай, арпа, солы, болын печәне. Китерәбез Т.: 8-927-470-08-25, 2-69-45.

***Жалюзи, барлык төрләр. Тиз. Т. 8-927-672-01-17.**

*Йомшак җиһаз. Т.: 2-45-47, 8-927-491-97-80.

*Кәрәз (Ульянныкы), 420 сум/кг. Т. 8-927-751-61-46.

*Инвалид арбасы, памперслар, флягалар, түшәк, суыткыч, келәм , палас. Т. 8-927-450-79-09.

*Таккычлар (Саранск, Курган). Т. 8-927-736-59-42.

*Утын. Т. 8-937-617-11-21.

*Төргәкләнгән печән. Т.: 8-987-004-84-64, 8-927-439-19-89.

*Яңа «Rebok» тимераяклары, 41нче үлчәм; кухня гарнитуры. Т. 8-917-928-10-54.

*Өлкәннәр өчен памперслар, 2ле. Т. 8-927-446-94-02.

*«Джили Эмгранд»га штампланган дисклар, штатлы CD-магнитола, яңалар. Т. 8-937-593-08-66.

*Утын. Т. 8-937-003-27-27.

*Өлкәннәр өчен памперслар, 2ле, данәсе 5 сум. Т. 8-927-491-97-89.

*Иткә яки нәселгә сарык тәкәсе. Т.: 8-927-245-32-03, 4-63-04 (өй).

### ТӨРЛЕСЕННӘН

***Йөк күчерү, «ГАЗель». Т. 8-937-570-60-21.**

***Йомшак җиһаз тарттыру, ремонтлау. Т. 8-937-570-60-21.**

*Йөкләр ташу, «ГАЗель», 4 м, 15 куб. Т. 8-927-247-12-61.

*Керамблоклар. Төяү, китерү. Т. 8-927-247-85-89.

*Тарттырылма түшәмнәр. Т. 8-9270-365-365 (Алексей).

*Сантехника, су, җылылык үткәрү. Т. 8-927-245-77-44.

*Төягеч хезмәтләре: кар чистарту. түгү. Т. 8-927-402-13-40.

*СТО хезмәтләре. Йөрү өлешен, тизлек тартмасын, двигательне ремонтлау. Сыйфатлы, кыйммәт түгел. Т. 8-927-032-31-70.

*Такси: Нурлат-Самара. Көн саен. Өегездән килеп алам. Т. 8-927-673-79-46.

*Өегезгә килеп суыткычлар төзәтәм. Т. 8-927-419-56-48.

*Суыткычлар төзәтәм. Т.: 2-71-69, 8-937-610-58-78.

*Суыткычлар төзәтәм. Т. 8-927-247-93-50.

*Кар көрибез. Т. 8-927-244-84-71.

*Электрик хезмәтләре. Т. 8-987-418-35-00.

*Мәче бирәм. Т. 8-937-527-41-90.

*Фатирлар ремонтлау . Т. 8-927-446-99-98.

*Коелар казыйбыз, чистартабыз. Т. 8-927-481-51-72.

***Йөк күчерү, «ГАЗель», 4,20 тент. Т. 8-927-442-38-10.**

*Сантехника (су, канализация, җылылык). Т. 8-937-526-56-86.

*Автоэвакуатор. Т. 8-927-246-51-99.

*Йөк күчерү, «ГАЗель», 4 метрлы, тентланмаган. Т. 8-927-401-97-48.

*Яшь кыз сатучы эше эзли (ашамлыклар түгел). Т.: 8-937-283-82-48, 8-927-243-09-71.

*Компьютерлар төзәтү, көйләү , Wi-Fi. Т. 8-937-0051-451.

### САТЫП АЛАМ

***Алгы приводлы «ВАЗ»лар, чит ил машиналары. Кыйммәткә. Т. 8-927-456-00-07.**

*Каз-үрдәк мамыгы, иске мендәрләр, түшәкләр. Т. 8-987-062-55-26.

*Таналар, үгезләр, сыерлар, атлар. Мөгезле эре терлек тиреләре. Т. 8-927-443-05-43.

### КИРӘК

*Оешмага даими эшкә ПОС монтажлау һәм хезмәт күрсәтү буенча белгечләр. Т.: 2-92-03, 8-919-636-70-17.

*«Перспектива» ООOсына «КамАЗ»га шофер, кранчы, экскаваторчы, эретеп ябыштыручы (тәҗрибә). Эш режимы 8.00дән 17.00гә кадәр, 2 ял көне (тору урыны бирелә). Элемтә өчен тел.: 2-58-21, 2-58-24. Адрес: Нурлат, Завод ур., 1.

*«Услуга» ООOсына медицина белеменә ия массаж ясаучы. Т.: 2-43-04, 2-43-03.

*«Нурлат элеваторы» ЯАҖнә даими эшкә стропальщик, аспираторщик, слесарь. 2-00-28 тел.буенча кадрлар бүлегенә мөрәҗәгать итәргә.

*Диспетчер-каравылчы, «Зүзәйнефть» бинасы, 1нче кат.

*«Нурлатнефть» НГДУсына скважиналарга агымдагы ремонт ясау цехына технолог. Таләпләр: белгечлек буенча югары белем, скважиналар ремонтлау өлкәсендә 3 елдан да ким булмаган стаж. «Нурлатнефть» НГДУсының кадрлар бүлегенә 92-067 тел. аша мөрәҗәгать итәргә.

*Ш/з.дан фатир. Т. 8-937-571-79-64.

### БИРЕП ТОРЫЛА

*Үзәктән тәүлекләп фатир, чеклар. Т. 8-929-727-47-80.

*Тәүлекләп фатир. Т. 8-927-406-11-06.

*Тәүлекләп 1, 2 бүлмәле фатирлар. Т. 8-927-456-59-10.

*Тәүлекләп фатир. Т. 8-927-448-33-48.

*2 бүлмәле фатир, үзәк. Т. 8-937-597-09-44.

*Командировкадагыларга сәгатьләп, тәүлекләп фатир. Т.: 8-927-456-05-69, 8-927-402-35-86.

*Массаж ясый торган кабинет. Т. 8-927-406-11-06.

*Арендага үзәктә бина. Т.: 2-07-89, 8-927-249-00-75.

*Үзәктә 1 бүлмәле фатир. Т. 8-929-724-84-17.

*Яшьлек мкр.да 2 бүлмәле фатир. Т. 8-927-414-73-53.

*3 бүлмәле фатир, Кариев ур., 59-10. Т. 8-927-414-73-53.


### ЮГАЛТУЛАР

*1997 елның 15 июнендә Чияле Алан урта гомумбелем бирү мәктәбе тарафыннан Сергей Васильевич Короткий исеменә бирелгән төп гомумбелем турындагы №2630794 аттестатны югалу сәбәпле гамәлдән чыккан дип исәпләргә.

*1975 елда Якушкино урта мәктәбе тарафыннан Ритта Владимировна Кирилова исеменә бирелгән сигезьеллык белем турындагы №905052 таныклыкны югалу сәбәпле гамәлдән чыккан дип исәпләргә.

